Ә УЛ БАТМАДЫ

Җомга иртәсеннән алып якшәмбегә кадәр бөтен Русия Тын океандагы хәлләрне күзәтте. Бортында җиде хәрби матрос булган батискаф су төбендәге ятьмә калдыкларына һәм тросларга буталган диделәр. Һәркем моннан 5 ел элек "Курск" атом су асты көймәсе белән булган вакыйганы исенә төшерде. Август, су асты көймәсе, хәрби флот... Туры килеп кенә торуын әйт син аның. Бу юлы хәрбиләр: "Ничек инде булышасыз, анда бит хәрби сер ята!" — дип авыз турсайтып чит илләрнең ярдәменнән баш тартмадылар. Һәм шуның аркасында гына җиде хәрбинең гомере өзелмәде. Бу юлы, ниһаять, кеше гомере хәрби сердән өстенрәк булып чыкты. Ярдәмгә Кушма Штатлар, японнар һәм инглизләр килде. Батискафны тозактан бары тик инглизләрнең "Скорпио" дигән су асты роботы гына йолып алган. Федерация Советының оборона һәм иминлек комитеты башлыгы урынбасары адмирал Вячеслав Попов "ИТАР-ТАСС" агентлыгына белдергәнчә, Русия 5 ел элек "Курск" белән булган фаҗигадән бернинди нәтиҗә дә чыгара алмаган. "Диңгез төбендәге операцияләрдә без яңадан чит ил ярдәменнән башка берни дә эшли алмаганлыгыбызны күрсәттек. Барысы да идарә итү һәм акча бирү осталыгына барып тоташа", — диде адмирал. Моны ишеткәч, бюджет Комитеты рәисе Евгений Бушмин: "Русиядә барысын да булдырып бетерү мөмкин түгел. Без бит бөтенләргә космоста булышабыз, алар да безгә булышырга тиеш", —дигән. Ә шул ук вакытта Тын океан флоты коткаручылары бүгенге мыскыллы хәлгә калуларына бик гарьләнгәннәр. "Бездә дә элек инглиз роботы кебек аппаратлар бар иде дә бит, үзгәртеп кору елларында аларны шалкан бәясенә сатып бетерделәр", — дип уфтанганнар алар ИТАР-ТАСС агентлыгына. Ярар, арты хәерле булгач әйбәт инде. Хәрбиләрнең держава өчен бераз рәнҗүен исәпкә алмаганда...



Татарстан яшьләре

* 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА * № 17 (10715) Бәясе килешү буенча

9 август, 2005 ел
СИШӘМБЕ

МЕҢЬЕЛЛЫКНЫҢ БӘЯСЕ — 7,7 МИЛЛИАРД СУМ!

Атна азагында Казанга федераль кунак — Русиянең финанс министры Алексей Кудрин килеп китте. Меңьеллыкка дигән акчаларның барысы да аның аша бирелә, шуңа күрә министрга башкалада бөтен урында да якты чырай гына күрсәттеләр. Федераль бюджеттан Казанның меңьеллыгына әзерләнүгә 7 миллиард 700 миллион сум акча бүленгән. Кудрин шул акчаларның ничек эшкә җигелүен карады. Баш казначы метрода да йөрде, яңа ипподромга да барды, яңа күпер аша да чыгып карады, яңа боз сарае да кереп күрде. "Туган авылым" ял комплексында Мәскәү кунагына мичтә пешкән коймак ашатканнар. Коймаклары төерле булмагангамы, Кудрин соңрак безнең адреска мактау сүзләрен кызганмады. Алексей Кудрин Казандагы үзгәрешләрне күреп шаккаткан. Аңа метро бигрәк тә ошаган. Президент Минтимер Шаймиев әйткәнчә, бу федераль үзәк белән килешеп эшләү нәтиҗәсе дә. Чөнки бер яктан Мәскәү меңьеллыкка акча бирсә, икенче яктан Татарстанның 2006 елга кадәр социаль-үсеш программасы нигезендә дә шактый зур сумма килеп барды. Киләсе елда аның соңгы өлеше — 6,5 миллиард сумы биреләчәк. "Сезнең киләчәккә үсеш өчен зур мөмкинлекләрегез бар, — диде Кудрин. — Ләкин алга таба инде республика һәм шәһәр үз көченә ышанып кына эшләргә тиеш". Ягъни, программалар тәмамлану белән, акчасы да бетә дигән сүз. Шулай да, Казанга инде бу көннәрдә 50 миллион доллар акча килеп җитәргә тиеш икән. Ул — Бөтендөнья банкы биргән кредитның беренче траншы. Финанс министры бу акчалар да халыкның тормышын яхшыртуга юнәлтеләсенә ышаныч белдереп, китеп барды. Алексей Кудрин Мәскәүдән бирелгән суммаларның эшкә тотылуын күрде инде. Кем белә, бәлки, күңеле йомшап, меңьеллыктан соң тагын берәр программа уйлап чыгарыр. Тикмәгә генә Минтимер Шәрипович: "Татарстан үзенең эшкә сәләтле икәнлеген күрсәтте. Без үзенә күрә бизнес-проект эшләп, аны башкарып чыгарга сәләтле булуыбызны исбатладык", — димәде бит.



"ЛОКОМОТИВ"ның парын чыгардык

6 август көнне Казанның Үзәк стадионында "Рубин" Русия беренчелегендә оттырышсыз егерме җиде (!) уен уткәргән "Локомотив"ны 3:1 исәбе белән тар-мар итте.

Казан футболчылары беренче минутларда ук һөҗүмгә ташландылар. Уникенче минутта кунаклар капкасына пенальти билгеләнде. Ансар Әюпов типкән тупны илнең иң көчле капкачысы саналган Овчинников та тотып кала алмады. 33 нче минутта Александро Домингес шулай ук штраф тибүеннән соң исәпне казанлылар файдасына 2:0 итте. Ә инде 80 нче минутта мәскәүлеләр капкасына өченче туп кергәч (авторы — Владимир Бәйрәмов) стадионга җыелган егерме меңләп тамашачының ничек шатлануын күрсәгез икән! Матч бетеп килгәндә генә кунаклар керткән бер туп "Локомотив"ны коткара алмый иде инде.


Сүз уңаеннан. "Локомотив"та уйнаучы татар егетләре — Марат Измайлов белән Динияр Билалетдинов хакында шимбә санында укырсыз.



Ш.АБДЮШЕВ фотолары.

Тавык башы түгел, кеше башы җәл

Әлеге дә баягы мәэзин абзый таягы дигәндәй, тавык чире Русияне тагын шөбһәгә салды. Новосибирск өлкәсендә тавык гриппы авыруы табылган. Аны Кытайдан кергән дип фаразлыйлар. Тавык гриппы барлык кош-кортны аяктан егып, юк итеп кенә калмый, кешегә дә йога. Вакытында ярдәм күрсәтергә өлгермәсәләр, кеше үлә. Татарстанда тавык гриппы таралуга каршы чаралар күрелә дип ышандыра республиканың авыл хуҗалыгы һәм Азык-төлек министрлыгы вәкилләре. Министр урынбасары Нәҗип Хәҗипов "Интерфакс" агентлыгына әйткәнчә, хәзер барлык тавык фабрикалары да ябык эш режимына күчерелгән. Анда теләсә кем кереп-чыгып йөри алмый, кошларның ризыкларын лабораторияләрдә кат-кат тикшерәләр. Тавык ите белән йомыркаларны да инә күзе аркылы уткәрәләр икән. Кыскасы, сакланганны саклармын диләр бит. Әле бер танышым көрсенеп сөйләп торды: "Бер көнне хатын тавык кыздырган иде, кухняда телевизор кабызып, шуны тәмләп кенә ашап утыра идем. Ә анда, каһәр, яңалыклардан тавык гриппы турында сөйлиләр. Бөтен аппетит югалды..." Яхшылап пешерсәң йә кыздырсаң, грипп микроблары үлә ди үзе. Татарстанга куркыныч чир килеп җитмәс дип өметләник. Юкса, сәламәтлек кенә түгел, ә тулы көченә аягына басып килгән кошчылык тармагы да куркыныч астына куела. Тагын шул сөяге каралып беткән Буш ботларына калмагаек диюем...



С. ГЫЙЛЬФАНОВ.

ШУЛның

телефон: 92-64-52

БАУЛЫ районы 75 еллык юбилеен билгеләп үтәргә әзерләнә. Бәйрәм тантаналары 20 августка билгеләнгән. Район халкы бигрәк тә танылган җырчы Алсуның килүен зарыгып көтә икән. Ул Ык елгасы буендагы мәйданда концерт бирергә тиеш.

ТҮБӘН КАМАДА сатудан 500 килограмм карбыз алынган. Эпидемиологлар тикшерү уздырган вакытта бер карбызда нитратлар табылган. Татлы җимеш үстерүчеләр зыянлы матдәләрне уколлар белән кадаган, имеш. Карбыз кабыгында укол эзләре дә калган. Белгечләр мондый очрак соңгы берничә елда беренче тапкыр булды дип ышандыра.

БУАДА июль азагында янгын аркасында тораксыз калган 16 гаиләгә бөтен район белән ярдәм итәләр. Биредә "Мәрхәмәтлелек" фонды ачылган. Теләгән һәркем хәленнән килгәнчә шул фондка акча күчерә ала.

БӨГЕЛМӘ СПИД чире күп таралган шәһәрләр арасында Республика буенча беренче урынга чыккан. Моннан өч ел элек кенә кара исемлеккә алдынгылык Чаллы кулында иде. Хәзер Чаллыны Бөгелмә белән беррәттән Әлмәт, Лениногорск һәм Казан узып киткәннәр.



Моңа кадәр субсидияләрен аванс рәвешендә алдан ук алып килгән льготачылар хәзер бу акчаларын һәр айның 10 сыннан 25енә кадәр аралыкта ала башлаячаклар. Ник дигәндә, социаль яклаучылар алданрак бирергә ашыгып, ЕДВ-субсидияләрне артыграк түләп ташлаганнар. 54 миллион сум "өсләренә чыккан". Хәзер башлары буталган ветеран-инвалидлар артык акчаларын дәүләткә кире кайтаралар. Бурычлы льготчылар 10 процентлап кына калган инде, күбесенең дәүләткә бирәсе акчасы 100 сумнан артык түгел икән.

Льгота акчаларының киш-миш килеп бетүенең бер сәбәбе — фатир өчен түләүләр шактый артканга күрә шәһәр халкы суга, газга, җылылык системасына счетчиклар куйдырта, гомумән, һәр нәрсәне экономияли башлаган. Нәтиҗәдә коммуналь

ЭТ БАШ, СЫЕР АЯК

хезмәтләр өчен түләү яхшы ук кимегән. Ә субсидия акчаларын халык әлеге исәп-хисапка кадәр үк алып куйган булган.

Акчаның "дәүләт өстенә" чыгуында халыкның да "ярдәме зур" икән: шома гына ике җирдән дә акча алып ятканнар ди. Әйтик, өлкән кеше ветеран һәм шул ук вакытта инвалид та икән, ул ике категориянең берсе буенча гына льгота акчасы алырга хокуклы. Ә бу акчалар дәүләтнең "ике кесәсеннән" түләнә: ветераннарга — соцяклау бүлегеннән, инвалидларга — Пенсия фондыннан.

Хәзер "тик торганда" бурычлыга әйләнгән кеше, социаль яклау бүлегенә барып, ни өчен артык акчалы булуын аңлатырга, аннан кулына тоттырылган квитанциясендәге сумманы "Ак Барс" банкындагы соцяклау органы счетына күчерергә тиеш була. Бурычын берьюлы түләп бетерергә хәленнән килми икән, соцяклау бүлегенә акчаны өч айда түлиячәге турында гариза яза ала. Әгәр бурычын кайтарырга аяк терәп каршы тора икән, Социаль яклау министрлыгы бу кешегә субсидия түләмәскә һәм аның счетын бикләп куеп, эшне судка тапшырырга хокуклы икән.

Йә Хода, тагын ниләр күрәсе бардыр...

Терәк бар, теләк юк

"Т. Я."ның бер санында Зөләйха Кыдашева татарча элмә такталарда, төрле белдерүләрдә көлке дәрәҗәсендә җибәрелә торган хаталарга әче пошып язган иде. Әйе, дөрес яза ул. Юкса, безнең туган татар телебез дөньядагы абруйлы телләрдән һич тә түбән-ким түгел. Әмма үзебез үк телебезне бозабыз! Минем татар телен бик тә яхшы белә торган бер урыс дустым бар. Ул миңа: "Сез нинди кешеләр соң, татарча җөмләгезне кырык хата белән язасыз", — ди. Әнә, "Центральный рынок"ны "Үзәк базары", Бакый Урманченың урысчасын "Баки Урманче", Кол Галинең урысчасын "Кул Гали" дип язасыз бит дип битәрләде. Әйе, Бакый аганы "Баки" дип куәмле су савытына (бак), кол сүзен "кул" дип язып, "Рука Галигә" әйләндерәбез. Билләһи, безнең мондый кыланышлыбыздан тавыклар көләрлек. Мондый мисалларны күпләп китерә алам мин. Нигә без, татарлар, шундый мескенлеккә тәгәрибез соң? Татар телебез дәүләт теле бит инде ләбаса! Сәбәп бер генә: без, татарлар — урыс менталитетының коллары. Чөнки без гомер буе урыс милләтен бөек урыс халкы дип әйтергә гадәтләнгән милләт. Ә бит җир шарында бер генә бөек халык та юк! Халкының саны ягыннан күпчелек һәм азчылык булган милләтләр генә бар. Шул күпчелек һәм азчылык халыкларның да дөньякүләм танылган бөек шәхесләре дә, мөртәтләре дә бар.

Мин югарыда "коллык" дигән сүз кулландым. Бүген Татарстаныбызда ике дәүләт теле — татар һәм урыс телләре. Йөз кеше катнашкан җыелышта бер яки ике башка милләт вәкиле (урыс дип укы) катнашса, җыелыш, һичшиксез, урыс телендә бара инде. Нишлисең, татарларның канына сеңгән коллык гадәте бу. Мисал өчен, Татарстаныбызның Югары Советы җыелышын гына алыйк. Бу җыелыш гел урыс телендә генә алып барыла. Нәрсә бу? Урыс милләтеннән булган депутатларыбыз томана түгелдер бит. Ватаҗимерә булса да татарча сөйләшергә өйрәнергә вакыттыр инде аларга. Сессияләрдә Разил Вәлиев, Туфан һәм Роберт Миңнуллиннар гына татар милләтеннән микәнни?! Гыйбрәт өчен, татар телен олылап, сессияне гел татарча гына алып бару тәртибен кертеп карарга иде, ә?! Татарча белмәгән депутатларга колакчыннар биреп, урысчага тәрҗемә итеп була ич. Дәүсовет депутатлары арасында татарлар илле процент чамасы дип беләм.

Дәүсовет рәисе Фәрит әфәнде (рәхмәт аңа, татарча бик әйбәт белә), уенын-чынын бергә кушып: "Әйдәгез, татар егетләре, татарча чыгыш ясарга өйрәнегез әле!" — дип өндәү ташласа, билләһи, аңа иярүчеләр булачак дим мин. (Татарча текст язып килеп булса да). Дәүләт теле булган туган телебезне тормыш агышына кертеп җибәрү өчен нык этәргеч булыр иде бу чаралар. Ә чараларның төрләре бик күп.

Озын сүзнең кыскасы шул: туган телебезне дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү өчен кыймылдый башларга вакыттыр инде. Ә моңа берминди дә каршылыклар юк кебек. Тик телебезгә игътибар һәм ихтирам белән карау теләге генә кирәк. Болай эшләү республикабызның барлык районнарына һәм башка оешмаларга да үрнәк булыр иде.

Әгәр дә татар телебезне чын мәгънәсендә киң кулланышка лаек дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрсәк, элмә такталарда да һәм башка урыннарда да тозсыз җөмләләр, сүзләр күренмәс иде.

Камил ГЫЙЛЬМУЛЛИН.
Түбән Кама.



АВТОР ФОТОСЫ.

ЮХИДИ ТИК ЯТМЫЙ

Казан янындагы "Спутник" лагеренда "Казан шәһәрен пропагандалау" дигән чара үткәрелде. Аны шәһәрнең Мәскәү районы эчке эшләр идарәсе оештырды. Инспектор Рәшит Хәмидуллин сүзләренә караганда, моның ише ярышуеннарны алар киләчәктә дә дәвам итәргә уйлыйлар. **Сүз уңаеннан:** 6 августта Мәскәү районының ЮХИДИ бүлеге "Сак бул, җәяүле!" дип аталган акция уздырды.

Марат МИНДУБАЕВ.

ЮМОРИСТ-ГУБЕРНАТОР ҺӘЛАКӘТТӘ ҮЛДЕ

Алтай крае губернаторы, танылган эстрада артисты Михаил Евдокимов үзенең машинасында бәрелеп үлде. Губернатор белән бергә шоферы һәм тән сакчысы да. Хатыны Галина авыр тән җәрәхәтләре алган. Евдокимов барган 600 нче Мерседес машинасы икенче бер автомобильне узарга дип каршы як полосага чыга. Шуның белән бәрелешмәс өчен, юл читенә борырга мәҗбүр була. Зур тизлектә барган Мерседес, юлдан очып чыгып, агачка бәрелеп челпәрәмә килгән. Мәетләрне махсус техника ярдәмендә машина кузовын кисеп алганнар. Әлеге факт буенча җинаять эше кузгатылган. Гадәттә, түрәләрнең машиналарында аеруча җитди иминлек чаралары күрелә бит. Ә монда автомобиль бер мизгелдә тимер өеменә әйләнгән. Тагын бер сәер нәрсә — губернатор машинасын башка җитәкчеләрнеке кебек ГАИ озатып йөрмәгән. Моннан атна чамасы элек Алтай крае эчке эшләр идарәсе Евдокимовны бу хокуктан мәхрүм итә. Шуны да искәртик, Алтай өлкәсенең закон чыгару органы депутатлары берничә мәртәбә Евдокимовны алып ташларга маташты. Алар хәтта Президент Путинга мөрәҗәгать итеп, аны эшеннән азат итүне сорадылар.

Яшел, әмма доллар түгел

1 августтан бөтен Русия буенча яңа "больничныйлар" бирелә башлый. Элеккеләре зәңгәр иде, болары яшел төстә.

Тагын шунысын да белеп торыйк: узган ел илдә табиблар авыруларга 37 млн. "больничный" кәгазе биргәннәр. Яңа бланкның берсен әзерләү дәүләт казнасына 37 тиенгә төшкән.

Мондый үзгәреш ни өчен кирәк булган соң? Әлбәттә, Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы моны беренче чиратта ялган авырулар һәм ришвәт алучы табибләр белән көрәшү максатыннан керткән. Яшел төстәге яңа больничныйда су билгеләре дә бар, димәк, аларны тиз генә ясап булмаячак.

Элек мондый кәгазьләр медицина учреждениеләрендә сакланса һәм аларны теләсә кемгә һәм теләсә нинди күләмдә бирсәләр, хәзер аларны дәвалау оешмалары үзләре социаль иминият фондлары бүлекчәләре аша гына ала алачак.

Дөресен генә әйткәндә, иске бланклар инде 40 елдан артык гамәлдә иде һәм андагы күп кенә пунктлар искерде.

БЕР ТЕМАГА ИКЕ ХАТ

"Дүрт татарның" ничәсе татар?

Русиядә татарга каршы тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү профессиональ җирлектә, киң планда дәүләт дәрәҗәсендә алып барылды; сабыйларны — төрле иллюстрацияле китаплар, укучыларны — дәреслекләр, гавәмне — әдәби, тарихи әсәрләр, газета-журнал, телерадиопрограммалар аша даими агарттылар һәм бу процесс әле туктамады да бугай.

Үткәрелгән мондый чараларны нейтральләштерүнең хәвефсез, әмма иң үтемле юлы — яһүд уйлап тапкан КВН уены.

Татарстанның "Дүрт татар" атлы командасының тәүге составы Мәскәү сәхнәләрендә уңышлы чыгышлары белән сөендергән иде. Ә Юрмалада ул иң дәрәҗәле призларны ике тапкыр яулады. Безнекеләр югары лигада үзләрен лаеклы тотты, ә "Золотая Орда" дигән җырлары милләттәш тамашачыларыбыз күңелләрен горурлык хисләренә тулыштырса, көндәш командаларны да уйларга мәҗбүр итте...

Алай да милли төсмере булган командалар күңелне ныграк җәлеп итә. Дөрес, кайбер шундый командалар җирле телне вата-җимерә ниндидер шамакай җыр башкарып тамашачыны көлдермәкче булып тырыша. Бәлкем түбәнрәк дәрәҗәдә, жюрида маңкортлар утырган очракта андый чыгышлар уңай бәяләнә дә торгандыр? Әмма Мәскәүдә, бигрәк тә Латвиядә андый "юмор" кабул ителми...

Югыйсә халкыбызның КВНда күрсәтерлек дөньякүләм шәхесләре бик күп. КВНда Шәймиевне дә, хирург Акчуринны да, балет осталары Рудольф Нуриев һәм Ирек Мөхәммәдовны, Русиянең эчке эшләр министры Рәшит Нургалиевны, академик Роальд Сәгъдиевны, аның хатыны — Сюзанны, шахматчы Гата Камскийны һәм тагын әллә кемнәребезне "катнаштырып" була.

Мондый бәйгеләр Татарстанны таныту һәм күрсәтү чарасы да бит һәм әлеге эш белән дәүләт, ә конкрет алганда аның яшьләр белән эшләүче министрлыгы шөгыльләнәдер дип фаразлыйм. Димәк, мондый команданы әзерләүдә Татарстанның сәнгать осталары катнашырга тиеш. Рас команда исемендә татар дигән сүз бар икән, ул инде Мәскәүгәме, Юрмалагамы, аларны "алам" дип барсын. Мескенлек, кимлек касәфәте аңа юлдаш булмасын иде. Нәрсәгә кирәк соң Татарстан командасына Филипп Киркоров булып маймыллану. Мөдәррис Әгъләмов бер шигырендә "элек бездә хакимияттә икейөзлеләр иде, хәзер йөзе юклар килде", — дип язды. Мин, ул әйткәндәй, командабызның "йөзсез" булуын теләмим.

Бәлкем "Дүрт татар" өчен номерлар әзерләшүгә, әйтик, "Татарстан яшьләре" газетасы аша милләттәшләребезне дә тартыргадыр? Шәхсән үземнең дә тәкъдимнәрем бар.

Татарстанда КВН хәрәкәтен координацияләү үзәге Татарстан телевидениесендә булырга тиеш. Шундагы җирлектә, бәлкем тора-бара менә дигән алып баручылар, шоуменнар, оригиналь тапшыру редакцияләре борын төртер иде...

Озын сүзнең кыскасы, безгә Масляков хозурындагы мәсләгебезне тәгаенләү фарыз...

Рөстәм ЗАРИПОВ.



Артык трусик юган өчен бит ул!



“Т.Я.”ның бер санында чыккан “Аккошка акча кирәкми” дигән хатта автор: “Ул парлыларга 200 сум акча өстәүләрен һаман аңламыйм” дип яза. Мин мондый хатларны күп укыдым инде. Хәзер илдә ирсез хатыннар һәм ялгыз ирләр бик күп. Үзем дә шуларның берсе. “Әйдә, кушылыйк”, — дип тәкъдим ясап карыйм, бераүләре: “Шәһәргә якын авыл булсын иде”, — диләр. “Берсеннән котылгач, икенчесенә чыгаммы соң!” — диючеләре дә бар. Өченчеләре: “Артык трусик юып ятмыйм әле”, — дип җиффәрәләр. Шулай булгач, аккошкайларым, хөкүмәткә үпкәләп, рәнҗеп ятмагыз. Ул 200 сум акчаны артык трусик юучыларга бирә. Парлашыгыз! Сез дә өстәмә 200 сум алырсыз. Илдә әле 60-70 процент ялгызлар парлашып яшәрлек. Ике казан асканчы бер казаннан ашавы тәмлерәк булыр, экономиялерәк тә. Бу — хөкүмәтнең аз булса да ялгызлар кимемәсме дип чыгарган кызыксындыру чарасы.

Ялгыз ир.
Кукмара.

Әни кайтып керер кебек

Безнең әниләребез Буа районы, Иске Суыксу авылында яшәделәр. Фатыйма Хисаметдин кызы Таҗетдинова — безне якты дөньяга тудыручы, гомер бирүче, ә Зәйнәп Әхмәтҗан кызы Таҗетдинова — үстерүче, олы тормыш юлына озатучы, җил-яңгырдан саклаучы әниебез. Зәйнәп әниебез җиде үги балага әни булып килгәндә иң олыбызга 18 яшь, иң кече сеңлебезгә яшь ярым булган. Ул безне чит-ят итмәде. Матур, тату гаилә булып гомер иттек. Хәзерге кайбер яшьләрнең газиз балаларын бала тудыру йортында, чүплекләргә ташлап китүләрен без берничек аңлый алмыйбыз, бу хәлне вәхшилеккә тиңлибез һәм җиде ят баланы үз канат астына алган әниебезгә баш иябез. Әниләребез якты дөньяда юк инде. Ә дөньяда әнине югалтудан да авыр нәрсә юк икән. Бу кайгы кайвакыт онытылып киткән кебек булса да, җил кузгаткан дулкыннар кебек өр-яңадан әйләнеп кайта. Әйләнеп кайта да йөрәкне чәнчеп-чәнчеп ала.

Авылга кайткан саен әниемнәрнең каберләре янынннан узарга туры килә. Мин алар белән күңелемнән генә сөйләшәм, серләшәм. Тәрбияләгән әниебез безгә бервакытта да каты бәрелмәде, берәр кылган гамәлебез дөрес булмаса, үзенең ягымлы тавышы белән кинәшләрен бирә иде. Ә менә хәзер шундый акыллы һәм кирәкле киңәшләр бирүче кешебез юк. Күп вакыт авылга кайткач, әни берәр кешегә генә киткәндер, менә хәзер елмаеп килеп керер кебек тоела.

Рәмзия ШӘРИПОВА.
Буа шәһәре.

Килегез, тараканнар беткән

Моннан берничә ел элек “Т.Я.”да Марий Элдагы “Кленовая гора” шифаханәсе турында мәкалә чыккан иде. Анда: “Шифаханә эчендә шакшылык, бүлмәләрдә тараканнар чабыша, ашханәдә аштан чәч, сасыган ит корты чыга...” дип язганнар иде.

Быел мин шул шифаханәдә ял иттем. Минем белән бергә Татарстан кунаклары да бар иде. Искиткеч әйбәт ял иттек. Тараканнар юк. Һәр җирдә чисталык һәм пөхтәлек. Ашлары тәмле, ризык төрләндерелә. Дәвалау алымнары бик әйбәт, шәфкать туташлары, башка хезмәткәрләр — барысы да диярлек мари хатын-кызлары.

Безнең Марий Элнең табигате бик матур бит. Шифаханәбез дә урман эчендә икән. Хатымны бастыра күрегез, белсеннәр, килсеннәр, ял итсеннәр, дәвалансыннар.

Фәүзия әбиегез НИГЪМӘТҖАНОВА,
пенсионер-укытучы, Марий Эл, Бәрәңге авылы.



“Каенанаңа бирерсең”

Базар шаулый, базар гөжли. Миңа, килгән кешегә, читтән күзәтү кызык. Менә савыт-саба сата торган җир. Матур итеп татарча сөйләшүләрен ишетеп туктап калдым. Олы яшьләрдәге татар апасы белән зәп-зәңгәр күзле, чибәр ханым чөкердәшә икән. Апаның күзе җете зәңгәр миләүшә чәчәге төшкән чәй чәйнегенә төште. “Бигрәкләр матур, кызым, мин алыйм әле бу чәйнекне”, — диде ул. Янындагы ханым: “И, әнкәй, алай ошаткач, үзем икегезгә дә алып бүләк итәм”, — дип, акча хәстәрли башлады. Боларның сөйләшүләренә сатучы да игътибар иткән икән. “Ал, сеңлем, ал, әниеңә бик ошады”, — диеп, чәйнекне шапылдатып прилавкага куйды. “Минем ике әнкәйгә дә бер төсле кирәк шул”, — диде ханым. Сатучы тартмалары арасында шактый гына кайнашканнан соң: “И, сеңлем, нәкъ шушындые юк, мә, бусының чәчәге тоныграк, ярар, монысын каенанаңа бирерсең”, — диеп икенче чәйнекне дә китереп куйды. Тегеләр көлешә башладылар. “Каенанасы мин аның, сеңлем”, — диде апа.

ГАРИФУЛЛА.
Казан.

Йөз чалгы аласы калган

Бу хөкүмәтнең хәйләкәрлеген әйтәм әле: пенсияләрне аз-маз арттырган була да, бәяләрне күтәрә. Элек, Брежнев заманында, бәяләрне, киресенчә, төшерү дигән нәрсә бар иде. Кибетләрдә бәясе төшкән (уцененный) товарлар тулып ята иде. Бервакыт Киров өлкәсендәге Нократ Аланы шәһәрендә чалгыны 1 тиенгә саттылар. Бишне алдым. Әле аларын да, юмартланып, кешеләргә биреп бетердем. Хәзер үзем иске-москы чалгылар белән чабып маташкан булам. Беркөнне кибеткә кергән идем, чалгы 180 сум тора — теге вакыттан бирле 18000 тапкыр күтәрелгән! Башым әйләнеп, күз алларым караңгыланып китте. Таягыма таянып, витринага тотынып кына калдым. Их, мин әйтәм, теге вакытта йөз чалгы алып куйган булсам!

Вакыйф ЗӘЙНУЛЛИН.
Кукмара районы, Мәчкәрә авылы.

Каравыл, талыйлар!

Беркөнне Буа-Казан поездында барганда, ике ревизор кереп билет тикшерергә кереште. Минем янәшәмдә утыручы, урта яшьләрдәге ир кешенең билеты юк иде, ревизор ханым бик сөенеп аңа бәяне аңлатты. Штраф суммасына билет бәясен һәм 30 сум “өстәмә хезмәтләр” дигәненнән дә кушкач түгәрәк кенә сумма килеп чыкты. Нишләсен, түләде абзыкай.

Ярый, барабыз шулай, Казанга җитәргә ерак әле, ревизорлар керде. Бу юлы икенче, яшьрәге тикшерә. Бик җентекләп карагач, штраф түләгән абыйның билеты тагын яраксыз булып чыкты, ул 30 сум “өстәмә хезмәтләр” өчен генә түләгән, имеш. Соңгы чиккә җиткән ачуын көчкә басып, билетсыз абый кабат штраф түләргә дип кесәсенә тыгылды. Түзмәдем, көпә-көндез кеше алдап, бер-берсенә акча эшләп йөргән ревизорларның монысын берничә сүз белән куып җибәрдем.

Икенче юлы бер иптәш белән Казан вокзалы кассасыннан билет алдык та, Казан-Буа поездына чаптык. Билет тикшереп торучы мине уздырды. Ә юлдашымны кертми, булмаган таныклыгын таптыра. Билетын карасак, “безденежный” дип язылган. Мондый билетны бушка йөрүче инвалидларга гына бирәләр. Кассир 70 сумын түләгән сәламәт дустыма да шул билетны биргән. Билетмы — билет, дустым аны-моны карамыйча кесәсенә салып куйган. Шуны кире кассага барып алыштырып килде, кассир берсүзсез алыштырган. Күрәсең, аның мондый кырын эш белән беренче генә шөгыльләнүе түгелдер. Ярый әле, ишеткән кергәндә ук тикшерделәр, юкса, юлдашым теге комсыз ревизорларга өчләтә түләгән булыр иде.

Рәсим ҖӘЛӘЛ.
Апас районы, Дәвеш авылы.

“Урысчада “ө” хәрефе юк бит”

Июль уртасында йомышым төшеп Актаныш автовокзалына кердем. Зурлап ремонт ясаганнар, бик күркәм, матур, күңелгә ятышлы. Шул ук вакытта вокзал эчендәге бөтен мәгълүматның урыс телендә генә язылганлыгы күзгә ташлана. Бердәнбер татар сүзе — “өчпочмак” — буфет витринасында гына очрады. “Ни эшләп монысын да урысча язмадыгыз?” — дигән сорауга буфетчы кыз: “урысчада “ө” хәрефе юк”, — диде.

Аңлавы кыен: ана телен саклау турында күп сүз барганда Актанышта татар теленә караганда урыс телен кулайрак күрәләр микәнни? Бу вокзалга көннәр буена бер урыс кереп карамаган чаклар буладыр.

Лимар ГЫЙМРАНОВ.
Актаныш районы, Актаныш авылы.

Малмыжга барам әле

Быел Киров өлкәсе, Малмыж районына әнинең туган авылына Сабантуйга барырга туры килде. Бу якның “данлыклы” юлларыннан бигрәк пенсионерларның автобуста ярты бәягә йөрүе шаккатырды. Кондуктор пенсия таныклыгын сорагач әни аптырап куйды. Льготалар бетерелгәннән бирле ул әнигә “ияреп” йөрми, шкафта тузан җыеп ята бирә.

Кызык: әллә монетизация реформалары анда барып җитә алмыйча сазлыклы юлларында батып калды микән? Әллә Киров өлкәсенең халыкны кайгыртабыз дип безгә үрнәк күрсәтүеме?

Рәмис ХАНТИМЕРОВ.
Кукмара районы, Чишмәбаш авылы.

20 елдан соң очрашу

Мәктәп еллары... Бу елларның никадәр кадерле икәнлеген еллар үткән саен ныграк аңлыйсың икән.

Быел без, ягъни Мамадыш районы, Көек-Ерыкса урта мәктәбен 1985 елда тәмамлаучылар, мәктәптә үзебезнең 20 елдан соң очрашуны билгеләп үтәргә булдык. Очрашуга укытучыларыбызны да чакырдык. Беренче укытучыларыбыз Кәүсәрия апа белән Дәлшат апа безне яңадан 1 класска “кабул итте”, аннары әкренләп класстан-класска “күтәрелдек”. Күпме истәлек, күпме хатирә...

Очрашу бик күңелле үтте. Иң сөендергәне шул: без бер-беребезгә тагын да якынайдык. Аерылышканда барыбызда да бер генә теләк иде: моннан соң да исән-сау күрешергә язсын!

ГӨЛИЯ.
Зәй районы, Югары Баграж авылы.



Иске Казанга сәяхәт–16

Меңьяшәр Казаныбыз үзенең ун гасырлык тарихында безнең өчен кабатланмас архитектуралы таш һәм агач корылмалары белән генә түгел, табигать тарафыннан бирелгән гаҗәеп матур сулыклары белән дә кадерле. Әйтик, инде без моңа кадәр сәяхәт оештырган Кабан күлләреннән тыш, борынгы Казаныбызда тагын берничә күл булган. Мәйданнары чагыштырмача кечерәк булган бу сулыклар хәзер инде халык телендә һәм географик иске язмаларда гына сакланганнар. Шулай булгач, бүгенге сәяхәтебезне күбрәк узган чорларга кайтып кына үткәрербез.

Казан Кирмәненең итәгендә Черек күл дип исемләнгән кечерәк бер сулык булуы мәгълүм. Кайбер галимнәрнең исәпләүләренә караганда, аның мәйданы 9 гектар чамасы булган. Черек күл тирәсендә җирне бораулап карагач, аның культуралы катламы гаять зур булуы, урыны-урыны белән утыз метрга җитүе беленгән. Күрәсең, бу шәһәрнең халык иң тыгыз утырган үзәк өлеше булгандыр...

Черек күлне Чишмә күленнән агып торган инеш туендырган. Зур булмаган Чишмә күле хәзерге Красин урамы тирәсендә, ягъни Черек күл батынкысының ян ягында була. Чишмә күле шәһәр күлләре арасында иң тәмле сулы күл булып саналганлыктан, аның суын казанлылар ипи салу өчен файдаланганнар. Ни кызганыч, XVI гасыр урталарында Чишмә күле бик нык пычранып бетә һәм аны 1774 елда күмәләр. XVI гасырда Казандагы өске күлләр чылбырында Чиста күл генә кала. Аны икенче төрле Николай күле дип тә йөртәләр. Бу күл тирәсендә тимерче һәм чүлмәкче алачыклары торганлыктан, тора-бара ул да шактый нык пычранган. Казанны алганда чишмә шартлатылу сәбәпле, камалышта калган шәһәр халкы суны шуннан алырга мәҗбүр булган. Николай күлен 1812 елда, ә кайбер мәгълүматлар буенча, 1842 елда күмгәннәр.

Хәзер инде Ирек мәйданы тирәсенәрәк барыйк. Биредә Черек күл системасына кермәгән тагын бер күл булган. Аның элеккеге исеме безнең чорга ук килеп җитмәгән, соңрак аны Бассейн дип (якындагы Бассейн урамының исеме дә шуннан алынган) атый башлаганнар. Ул чордагы халык, әлеге мәйданда театр бинасы булу сәбәпле, аны Театр күле дип тә йөрткән. Аның арткан суы Касаткин урамы буйлап, Казансу елгасына агып торган. Монысын XIX гасыр уртасында күмгәннәр.

Әлеге юкка чыккан күлләрнең язмышы безгә, хәзерге буынга, гыйбрәтле бер кисәтү булып тора.

Әлбәттә, бүгенгесе көнгә кадәр сакланып калган күлләрдән Болак ягына кузгалсак, сәяхәтебез вакытында Казан тарихын тагын да күбрәк белә алырбыз.

Болак күле Казан дивары яныннан ук агып торган. Ул да Казан халкын су белән тәэмин итүдә зур роль уйнаган. Болакның уң ягында тыгыз урнашкан Түбән тышкы шәһәр, сулда Кыраши бистәсе булган. Шушы тирәдә яшәүчеләр Болактан су алган. Шул ук вакытта, суны да кире Болакка түккәннәр.

Зур эзләнүләр вакытында, археологлар Кирмән тавында агач улак таптылар. Бу улак хан сараеннан, шулай ук Кирмәннең башка җәмәгать корылмаларыннан Болакка таба сузылган. Күрәсең, бу Казандагы беренче канализация коллекторы булгандыр. Шәһәрнең төп өлеше, әлбәттә, мондый "уңайлыктан" мәхрүм була, бөтен пычрак агынтылар ачык канаудан шул ук Болакка яки Черек күл батынкысына агып тора. Менә шуңа да, Болак инде XV гасырда ук, эчә торган су чыганагы булудан туктап, асылда канализация канауына әйләнеп кала. Алай гына да түгел, Болак бик нык саега да. Аңа кадәр Болак мөһим транспорт юлы була бит: кораблар Иделдән һәм Казансу елгасыннан аның аша үтеп, Якын һәм Урта Кабанга да чыгып йөргәннәр.

Күз алдына китерик: ул чорларда без басып торган Болак күле ярларында бөтенләй икенче төрле манзара булган. Хәтта анда су тегермәннәре дә эшләп торган. Әйтик, шундый ике тегермән сан алу кенәгәләренә дә теркәлгән. Бер җил (су) тегермәне хәзерге педагогика университетының төп бинасы янында, ә икенчесе Болак тамагы янында булган. Көймәләр үтеп йөри алсын өчен махсус шлюзлар да төзелгән. Шлюзларда су тирәнлеге ике метрдан да ким булмаган, бу исә шактый зур Идел корабларына да Болакка керергә мөмкинлек биргән. Кала халкы Болак ярларына мунчалар да төзеп куйган. Алар арасында иң данлыклы булган Таһир мунчасы элеккеге тарихи язмаларда кат-кат телгә алына. Ул борынгы болгар мунчалары үрнәгендә төзелә. Аның идәне җылытыла, гөмбәзләре биек итеп, бассейннары, фонтаннары да була. Мунчага балчыктан яндырып ясалган торбалар аша суның салкыны да, кайнары да килеп тора һәм махсус өрдергечтән кайнар һава да өстәлә. Мунчаның алгы бүлмәсендә (хәзергечә әйтсәк, вестибюльдә) шәп кенә җиһазланган ял почмагы да була. Таһир мунчасына халыкның югары катлавы йөри, шунлыктан, алар өчен бу үзенә күрә клуб булып та хезмәт итә: монда яңалыклар алмашалар, мөһим мәсьәләләрне хәл итәләр, җыр-музыка һәм яңа шигырьләр тыңлыйлар.

XV гасыр азагына Болак нык саега, Кабан күле буендагы Әрмән бистәсенә һәм башка торак пунктларга көймәләр белән йөзеп бару кыенлаша. Шуңа күрә аны чистарту һәм тирәнәйтү ихтыяҗы туа. Ә XV-XVI гасырлар чигендә Болакка беренче реконструкция үткәрелә. Төньяк урманнарыннан куып китерелгән "меңнәрчә чирмеш" һәм көньяктан килгән нугайлар, хан нәзирләре күзәтчелеге астында, яңа су юлы казып, Болакны канал рәвешендә турайталар. Тышкы шәһәр әйләнәсен дивар белән уратканда, Болак ярын да бурап, ныгыталар, күл төбен пычрак ләмнән арындырып, имән ярка түшиләр. Шул рәвешле, Болакны тирәнәйткәч, аннан тагын кораблар үтеп йөри ала башлый, әмма бу озакка бармый. Күл төбе янә пычрана. Бары тик көймәләр генә Болак буйлап XX гасырның 20 нче елларына кадәр йөреп торганнар.

Ә Болак буендагы табигать XVI гасыр башларында карап туймаслык була. Биредәге Хан болыны (урыс елъязмаларында Царев луг) үзенең искиткеч матурлыгы белән аерылып тора. Анда Сабантуйларын һәм каланың бүтән бәйрәмнәрен үткәрә торган булганнар. Бер "Казан елъязмачысы" болай дип язып калдырган. "Болактан Идел тарафынача искитмәле, күренекле вә олуг Хан болыны җәйрәп ятыр, ул җиде чакрымнар тирәсе булыр, мул үләнгә күмелеп, ямь-яшел булып утырыр, төрледән-төрле чәчәкләрдән келәм җәйгән төсле булыр... Бик борынгы документлардан күренгәнчә, ханның ат абзарлары өчен бу тугайның һәр дисәтинәсеннән утызар чүмәлә печән чабып алынганлыгы да мәгълүм.

Ни кызганыч, XVI гасыр азагында, Болак аръягында Татар бистәсе барлыкка килгәч, әлеге тугай табигый матурлыгын җуя, чүп түгү урынына әверелә.


XVII-XVIII гасырларда Болак аша берничә агач күпер дә салалар. Еллар үтү белән күперләр ныклыгын югалталар һәм хәзер инде алар урынына салынган заманча тимер-бетон күперләр бу тирәгә үзенчәлекле матурлык өстәп торалар.

Соңгы вакытларда Болак күле ярларын яшелләндерү һәм төзекләндерү өчен бик күп эшләнә. Әйтик, аның ярларын чирәм белән түшәүгә генә миллионлаган сум акча тотылды. Шулай ук аның төбен чистарту, даими рәвештә өслеген чистартып тору өчен дә зур суммада финанслар таләп ителә.

Күл сай һәм тар булса да, язын аның түбән өлешендә балыклар мыжлап торганын күзәтергә мөмкин. Анда -санда күлгә кыр үрдәкләре төшеп бәбкә чыгарган очраклар да бар. Кыскасы, вакыт-вакыт ул үзенең беренчел матурлыгын сагынгандай, узган чорларга да кайтып-кайтып ала кебек.

Дамир ФӘСИЕВ.
Казан.

Л.НУРИӘХМӘТОВ фотолары.



Московский Государственный Университет Экономики Статистики и Информатики

Региональный институт развития открытого образования

ВЫСШЕЕ ОБРАЗОВАНИЕ
АКСУБАЕВО 28901
АЛЬКЕЕВО 23560
АРСК 31748
БАВЛЫ 58173
К.УСТЬЕ 21247
КУКМОР 27870
МАМАДЫШ 35161
НУРЛАТ 29034
ПЕСТРЕЦЫ 21479
Р.СЛОБОДА 22198
Б.САБЫ 23698
ЧЕРЕМШАН 25769

- БУХГАЛТЕРСКИЙ УЧЕТ, АНАЛИЗ И АУДИТ
- ФИНАНСЫ И КРЕДИТ
- МЕНЕДЖМЕНТ ОРГАНИЗАЦИИ
- МАРКЕТИНГ
- ПРИКЛАДНАЯ ИНФОРМАТИКА
- СТАТИСТИКА
- ЮРИСПРУДЕНЦИЯ

Прием документов до 1 октября

Диплом государственного образца

Обращаться: **г.Казань, ул.Бутлерова 30. Тел. 48-65-65. 60-69-23. E-mail: mmc@riroo.kazan.ru**

ЛИЦЕНЗИЯ МЭСИ № 2273 ОТ 26.05.04 Г.
ЛИЦЕНЗИЯ РИРОО № 2550 ОТ 21.04.04 Г.



Укучыбыз көчтәнәче

Шәһәрдән авылга кайткан студент — дәү әнисенә:

— Дәү әни, син миңа утыр, әйдә, аша дип әйтәсең әйтүен дә, табыныңда минем специальность буенча берни дә күренми әле монда.

* * *

Әнисе — кызына:

— Кызым, үзең кискотага (дискотекага) барам дисең, ә үзең кыска балаклы ирләр чалбары кигәнсең. Алгы яктан — кендегең, арткы яктан аркаң күренеп тора, әллә теге минем озын җиңле, киң итәкле күлмәкне генә киясеңме, аның белән җайлырак булыр иде диюем.

* * *

— Иске кәгазь бер тәңкә белән яңа тимер бер тәңкә арасында нинди аерма бар?

— Иске кәгазь бер тәңкәгә 3 кило килька алып була иде, ә хәзерге яңа тимер берлеккә 3 кенә килька килә.

Фәрит ЮНЫСОВ.
Апас.

Кукмара көнкүреш йортында (хәзер ООО "Сервис") 32 ел буе фотосурәтче Сафин Рәфкатька яшь хатын мөрәҗәгать итә:

— Абый, балаларны төшерәсезме?

— Сеңлем, монда бала төшермиләр. Сезгә гинекологиягә барырга кирәк.

* * *

Шул ук Сафинга бер ир егет керeп:

— Мин сезгә олы йомыш белән килдем әле! — ди

— Олы йомыш белән бездә арт якка чыгалар...

* * *

Элегрәк фотографиядә "приемщица" квитанция язып бирә торган булган. "Приемщица" Айсылу клиенттан:

— Адресыгыз?

— М.Чура! — ди Малая Чура авылы кешесе.

Айсылу, бераз икеләнеп торганнан соң:

— Бичурадыр ул, абый?

Мәгъсум ХӘБИБУЛЛИН.
Кукмара.

ЯЗЫГЫЗ:
420066, КАЗАН, ДЕКАБРИСТЛАР УРАМЫ, 2. «ТАТАРСТАН ЯШЬЛӘРЕ».

ЧЫЛТЫРАТЫГЫЗ:
92-64-52, 43-56-35 — БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЛАРЫ (СӘЯСӘТ-ИКЪТИСАД)
92-36-50 — ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП, КОМПЬЮТЕР ОПЕРАТОРЛАРЫ
92-37-58 — ХАТЛАР БҮЛЕГЕ, ТӘРҖЕМӘ
43-53-66 — КОРРЕКТОРЛАР
92-41-52 — КОМПЬЮТЕР ОПЕРАТОРЛАРЫ
92-36-48 — БУХГАЛТЕРЛАР (РЕКЛАМА)
19-45-42 — МӘДӘНИЯТ-СӘНГАТЬ, АВЫЛ ТОРМЫШЫ
19-45-43 — ФӘН-МӘГАРИФ
43-56-35 — ФАКС
19-45-40 — "Т.Я." ПЛЮС" НӘШРИЯТ ЙОРТЫ

www.tatyash.ru
e-mail: tatjash@tbit.ru

РЕДАКЦИЯНЕҢ ИСӘП-ХИСАП СЧЕТЫ:
Р/С 40703810762260100479, КПП 165801001,
К/С 30101810600000000603, ОСБ "Банк Татарстан"№8610
Г.КАЗАНЬ, ИНН 1658033864, БИК 049205603

«Татарстан яшьләре»н гамәлгә куючылар – Татарстан Республикасының яшьләр оешмалары советы, "Т.Я." плюс" нәшрият йорты коллективы.

Газета Русия Федерациясенең Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министрлыгында ПИ-7-2574 нче номерлы таныклык белән теркәлде.

«Т.Я.» сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга.

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән рөхсәт алу мәҗбүри.

Реклама һәм белдерүләрдәге мәгълүматларның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

"СТРОЙ-К" фирмасыннан алынган кәгазьдә басылды.

"Т.Я."га теләсә кайчан язылырга мөмкин. Бу айның 15 нче числосына кадәр язылсагыз, ул сезгә алдагы ай башыннан килә башлый.

Бу чыгарылышны баш мөхәррир урынбасары А.ГАФИЯТОВ әзерләде.

Индекс — 54 121
Тираж — 51 108

Баш мөхәррир Исмәгыйль ШӘРӘФИЕВ

ТЯ

ЗАКАЗ 1144

"ИДЕЛ - ПРЕСС" ААҖ БАСМАХАНӘСЕ, КАЗАН, ДЕКАБРИСТЛАР УРАМЫ, 2

ГАЗЕТА БАСЫЛУГА КУЛ КУЮ ГРАФИК БУЕНЧА 15 СӘГАТЬТӘ. БУ САНГА 14 СӘГАТЬТӘ КУЛ КУЕЛДЫ.